| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

18 декабрь 2020 ел №4/4

Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 гыйнварындагы 52/5 номерлы карарына коррупциягә каршы экспертиза нигезендә, Чүпрәле районы прокурорының 2020 елның 16 декабрендәге 02-01-16/2020 номерлы таләбен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 апрелендәге 39/1 номерлы (04.09.2018ел № 45/2, 18.01.2019 ел № 52/5, 13.11.2020ел №3/5 редакциясендә) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр билгеләү турында» карары белән расланган «Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе һәм шартлары» дигән 12 нче кушымтаның 1 нче пунктына үзгәрешләр кертү хакында " гы карарга «муниципаль вазыйфаны биләүче затның эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Иске Чүпрәле авыл җирлеге**
**Башлыгы урынбасары : Р. Д. Низамов**